Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Советы

# КАРАР

2018 елның 16 августы № 28/6

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларын шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен куллану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Су кодексының 27 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә, Чүпрәле районы прокурорының 23.07.2018 ел, № 02-08-03-2018 судан файдалану турындагы законнарны бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2010 елның 27 апрелендәге 49/5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларын шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләренең 2 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4 һәм 2.5 пунктчаларын тешереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 2.6 һәм 2.7 пунктлары белән тулыландырырга:

«2.6. гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буйларына ирекле үтемлелеген тәэмин итү;

2.7. муниципаль район чикләрендә авылара территорияләрдә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларында судан файдалануны чикләү турында халыкка хәбәр итү.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Башлыгы урынбасары,
Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Советы Рәисе урынбасары: А.И. Сарафанов